Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

4 октябрь, 2023 ел № 7

Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 59 номерлы карары (2021 елның 14 декабрендәге 41 номерлы карар белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Колай авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Олы Дүртөйле авылында. 2023 елның 21 октябрендә 09.30 сәгатьтә Кооператив урамы, 2А йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Олы Дүртөйле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасындагы студентлар һәм мәктәп укучыларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Арышхазда авылында. Халык җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2023 елның 21 октябрендә 11.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 15А йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Үзәк, Колхоз урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2023 елның 22 октябрендә 09.30 сәгатьтә Үзәк урамы, 15А йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Елга арты, Чокыр арты, Бакча урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Арышхазда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Карповка бистәсендә. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын ике этапта үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2023 елның 21 октябрендә 12.30 сәгатьтә Совет урамы, 37А йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2023 елның 21 октябрендә 13.00 сәгатьтә Совет урамы, 37А йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Урман, Күл урамы йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Карповка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.4. Тогашево авылында. 2023 елның 22 октябрендә 11.00 сәгатьтә Космонавтлар урамы, 51А йорты буенча урнашкан кибет янында халык җыенын үткәрергә:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Тогашево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә житкән гражданнарны, 1 төркем инвалидларны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм жирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.5. Колай авылында. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын сигез этапта үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2023 елның 28 октябрендә 10.00 сәгатьтә Яшьләр урамы, 26Б йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшьләр урамының 26-113 йортлары, Юл урамының 1 номерлы йорты буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2023 елның 28 октябрендә 11.30 сәгатьтә Яшьләр урамы, 26Б йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшьләр урамының 3а-25 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2023 елның 28 октябрендә 13.00 сәгатьтә Яшьләр урамы, 3Б йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшьләр урамының 1-3 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының дүртенче этабы 2023 елның 28 октябрендә 14.30 сәгатьтә Совет ур., 34 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамы, Яшел урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының бишенче этабы 2023 елның 29 октябрендә 10.00 сәгатьтә Чкалов урамы, 7 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Чкалов урамы, Профсоюз урамының 1-29 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының алтынчы этабы 2023 елның 29 октябрендә 11.30 сәгатьтә Чкалов урамы, 1А йорты буенча урнашкан авыл мәдәният йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Тау асты урамы, Полужная урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының җиденче этабы 2023 елның 29 октябрендә 13.00 сәгатьтә Профсоюз урамы, 33 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Профсоюз урамының 32-34 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының сигезенче этабы 2023 елның 29 октябрендә 14.30 сәгатьтә Профсоюз урамы, 36 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Профсоюз урамының 35-37 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Колай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В. Поповская